# КАРАР

**25 ноябрь 2021 ел** **№2**

**Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 650 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Күкшел авылы Полевая урамына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Күкшел авылы Заречная урамына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Күкшел авылы Пушкина урамы , вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Күкшел авылы Садовая урамы , вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Су башнясы өчен насос алу (килешү буенча түләү);
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру;
- Күкшел авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);
-Әфган сугышында катнашучыларга мемориаль такта алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Зиратларны карап тоту,агач кисү, җирләү кирәк-яраклары өчен склад бинасы төзү һәм инвентарь алу (килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 621 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 438 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 438 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 650 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Күкшел авылы Полевая урамына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Күкшел авылы Заречная урамына вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Күкшел авылы Пушкина урамы , вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Күкшел авылы Садовая урамы , вак таш җәелгән юлларның профилен төзәтү (килешү буенча түләү);
- Су башнясы өчен насос алу (килешү буенча түләү);
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Ленин ур., 48а адресы буенча универсаль спорт мәйданчыгы өчен спорт инвентаре сатып алу һәм урнаштыру;
- Күкшел авылындагы юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү);
-Әфган сугышында катнашучыларга мемориаль такта алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Зиратларны карап тоту,агач кисү, җирләү кирәк-яраклары өчен склад бинасы төзү һәм инвентарь алу (килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Күкшел авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хәмидуллин